Татарстан Республикасы Ютазы Район Советы

IV чакырылышның чираттан тыш утырышы
КАРАРЫ

«16» апрель 2024 ел                                                                      № _4__

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты структурасына үзгәреш кертү турында**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законының 37 маддәсе, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 25 маддәсе, «Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июлендәге 313 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 29 декабрендәге 1721 санлы карары, министрның Беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык Департаменты директоры М.Д. Фәйзрахмановның 2024 елның 8 февралендәге 08-14/475 санлы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты структурасына түбәндәге үзгәреш кертергә: «архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенең баш белгече» штат берәмлеген 2024 елның 17 апреленнән төшереп калдырырга.
2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Самонина С.П. Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының штат расписаниесен расларга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Ютазы район Советының законлылык, регламент һәм җирлекләр Советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы башлыгы –
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе                                        А.Ә. Шәфигуллин